**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 декабрендәге 4708 номерлы карары**

**2026 елда «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2021 елның 3 ноябрендәге 2906 номерлы «“Казан шәһәрен үстерү институты” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 25 сентябрендәге 3162 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге карарның кушымтасы нигезендә «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) 2026 елга норматив чыгымнарны расларга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 29 декабрендәге
4708 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) 2026 елга норматив чыгымнар**

| № т/б | Муниципаль эш (хезмәт) исеме | Муниципаль эш (хезмәт) эчтәлеге | Норматив чыгымнар (елына сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | Территорияләрне планлаштыру документларын әзерләү | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү | 14 935 604,93 |
| | | Территорияне ызанлау проектын әзерләү | 4 035 496,10 |
| | | Инженерлык-геодезик тикшеренүләр» | 5 220 118,50 |
| 2 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | 13 235 595,40 |
| 3 | Кадастр эшчәнлеген башкару | Дәүләт кадастр исәбен башкару өчен кирәкле белешмәләр булган документларны әзерләүдә күчемсез милеккә карата эшләр башкару | 18 636 828,52 |
| 4 | Эшчәнлекне административ яктан тәэмин итү | Проектлар белән идарә итү | 81 382 269,03 |
| | | Анализ үткәрү | 16 206 120,01 |
| | | Мониторинг үткәрү | 9 701 446,13 |
| 5 | Архитектура-төзелеш буенча проектлаштыруны башкару | Күчемсез милек объектларының проект-смета документларын эшләү | 88 694 821,38 |

___________________